КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 7 июнь г.Казань № 479

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Спортның олимпия төрләре буенча спорт әзерлеге дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын раслау турында» 2017 ел, 19 июль, 509 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Спортның олимпия төрләре буенча спорт әзерлеге дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын раслау турында» 2017 ел, 19 июль, 509 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Стандартны» сүзен «Спортның олимпия төрләре буенча спорт әзерлеге буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандарты» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктны түбәнрдәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына йөкләргә.»;

әлеге карар белән расланган Спортның олимпия төрләре буенча спорт әзерлеге дәүләт хезмәте сыйфаты стандартын яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 19 июль, 509 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 7 июнь, 479 нчы
карары редакциясендә)

# Спортның олимпия төрләре буенча спорт әзерлеге дәүләт хезмәте сыйфаты стандарты

## 1. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмаларында дәүләт хезмәте алучылар

1.1. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмаларында спортның олимпия төрләре буенча дәүләт хезмәтен (алга таба – дәүләт хезмәте) алучылар – спорт әзерлегенә керешүче шәхси сайлап алуны узган физик затлар (Россия Федерациясе гражданнары).

1.2. Дәүләт хезмәтен алучыларның яше Россия Федерациясе Спорт министрлыгы боерыклары белән расланган олимпия спорт төрләре буенча спорт әзерлегенең федераль стандартлары нигезендә эшләнгән спорт әзерлеге программалары нигезендә билгеләнә.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы хокукый актлар

2.1. Дәүләт хезмәте түбәндәге закон, норматив хокукый актлар, методик һәм инструктив документлар нигезендә күрсәтелә:

БМО Генераль Ассамблеясы тарафыннан хупланган Бала хокуклары турында Конвенция 20.11.1989;

Россия Федерациясе Конституциясе;

«Балигъ булмаганнарның караучысызлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Физик затларга күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең гомумроссия база (тармак) исемлекләрен (классификаторларын) һәм физик затларга күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең Гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт хезмәтләренең федераль исемлекләрен (классификаторларын) һәм эшләрен һәм Россия Федерациясе норматив хокукый актларында күрсәтелгән эшләрне формалаштыру, алып бару һәм раслау турында» 2017 елның 30 августындагы 1043 номерлы карары;

Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының «СанПиН 2.1.2.1188-03не гамәлгә кертү турында» 2003 елның 30 гыйнварындагы 4 номерлы карары;

Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының «Балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының эш режимын урнаштыруга, карап тотуга һәм оештыруга карата санитар-эпидемиологик таләпләр» СанПиН 2.4.4.3172-14 раслау турында» 2014 елның 4 июлендәге 41 номерлы карары;

Россия Федерациясе Спорт министрлыгының «Россия Федерациясе төзегән һәм спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы физкультура-спорт оешмаларына затларны кабул итү тәртибен раслау турында» 2013 елның 16 августындагы 645 номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Спорт министрлыгының «Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның спорт әзерлегенең федераль стандартларын үтәвен контрольдә тоту тәртибен раслау турында» 2013 елның 16 августындагы 636 номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Спорт министрлыгының «Физик культура һәм спорт өлкәсендә белем бирү, тренировка һәм методик эшчәнлекне оештыру һәм гамәлгә ашыру үзенчәлекләрен раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1125 номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Спорт министрлыгының «Россия Федерациясе спорт җыелма командалары өчен спорт резервын әзерләүне тәэмин итүгә таләпләрне раслау турында» 2015 елның 30 октябрендәге 999 номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче затларга (шул исәптән физкультура чараларын һәм спорт чараларын әзерләгәндә һәм үткәргәндә) медицина ярдәме күрсәтүне оештыру тәртибе турында, спорт әзерлеген узарга, оешмаларда физик культура һәм спорт белән шөгыльләнергә һәм (яки) «Хезмәткә һәм оборонага әзер» Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынау (тестлар) нормаларын үтәргә теләгән затларны медицина тикшерүе тәртибен кертеп» 2016 елның 1 мартындагы 134н номерлы боерыгы,

Россия Федерациясе Спорт министрлыгы боерыклары белән расланган спортның олимпия төрләре буенча спорт әзерлегенең федераль стандартлары;

ГОСТ Р 52024-2003 «Физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт хезмәтләре. Гомуми таләпләр»;

ГОСТ Р 52025-2003 «Физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт хезмәтләре. Кулланучылар куркынычсызлыгы таләпләре»;

Татарстан Республикасы Конституциясе;

«Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфаты стандартлары турында» 2009 ел, 30 июнь, 445 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килү-килмәүне бәяләү тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының учреждениеләре төрләре һәм аерым дәүләт учреждениеләре арасында дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең якынча исемлеген раслау турында» 2015 ел, 29 сентябрь, 726 нчы карары.

3. Дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

| Т/с | Документлар исемлеге | Документ бирүче оешма | Документны биргән көннән алып аның гамәлдә булу срогы |
|---|---|---|---|
| 1. | Граждан шәхесен раслаучы документ: | | |
| | Россия Федерациясе гражданы паспорты (14 яшьтән һәм өлкәнрәк); | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары | 14 яшьтән һәм өлкәнрәк, законнар нигезендә |
| | туу турында таныклык | гражданлык хәле актларын теркәү органнары | 14 яшькә кадәр |
| 2. | Ата-ана, опекун яки попечитель гаризасы; шәхси гариза (14 яшьтән балалар өчен) | – | вакыты чиксез |
| 3. | Сайланган спорт төре буенча спорт әзерлеге узуга рөхсәт турында медицина бәяләмәсе | медицина оешмасы | 1 ел |
| 4. | Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасына керүченең фоторәсемнәре (оешма тарафыннан билгеләнгән санда һәм форматта) | – | вакыты чиксез |

4. Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү тәртибенә һәм шартларына карата таләпләр

4.1. Дәүләт хезмәтен түбәндәге дәүләт оешмалары (алга таба – спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы) күрсәтә):

спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт учреждениеләре;

физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлек башкаручы өстәмә белем бирү дәүләт учреждениеләре;

«Казан олимпия резервы көллияте» дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе.

4.2. Дәүләт хезмәте түбәндәге максатларда күрсәтелә:

а) башлангыч әзерлек этабында:

спорт белән шөгыльләнүгә карата тотрыклы кызыксыну формалаштыру;

спортның олимпия төрләре буенча техника нигезләрен үзләштерү;

физик сыйфатларны һәрьяклап гармонияле үстерү;

спортчыларның сәламәтлеген ныгыту;

спорт төре буенча алга таба шөгыльләнү өчен перспективалы яшь спортчыларны сайлап алу;

б) тренировка этабында (спорт специализациясе этабында):

гомуми һәм махсус физик, техник, тактик һәм психологик әзерлек дәрәҗәсен күтәрү;

спорт төре буенча рәсми спорт ярышларында чыгыш ясау тәҗрибәсен туплау һәм тотрыклылыкка ирешү;

спорт мотивациясен формалаштыру;

спортчыларның сәламәтлеген ныгыту;

в) спорт осталыгын камилләштерү этабында:

спортчылар организмының функциональ мөмкинлекләрен арттыру;

гомуми һәм махсус физик сыйфатларны, техник, тактик һәм психологик әзерлекне камилләштерү;

төбәк һәм бөтенроссия рәсми спорт ярышларында югары спорт нәтиҗәләрен күрсәтүнең тотрыклылыгы;

спорт мотивациясенең югары дәрәҗәсен саклап калу;

спортчыларның сәламәтлеген саклау;

г) югары спорт осталыгы этабында:

Россия Федерациясе спорт җыелма командалары дәрәҗәсендәге нәтиҗәләргә ирешү;

бөтенроссия һәм Халыкара рәсми спорт ярышларында югары спорт нәтиҗәләрен күрсәтүнең тотрыклылыгын арттыру.

Этапларның озынлыгы (елларда) спорт әзерлегенең федераль стандартлары (спорт төрләре буенча) белән билгеләнә.

4.3. Спорт әзерлеге этапларын тәэмин итү өчен спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмалары югары спорт нәтиҗәләренә ирешү өчен перспективалы спортчылар составын билгеләү һәм максатчан эзләүдән гыйбарәт булган спорт сайлап алу системасын кулланалар.

Спорт сайлап алу системасы үз эченә ала:

а) егетләрне һәм кызларны спорт белән шөгыльләнүгә юнәлтү максаты белән массакүләм карау һәм тест үткәрү;

б) спорт төре буенча спорт әзерлеге төркемнәрен комплектлау өчен перспективалы яшь спортчыларны сайлап алу;

в) тренировка җыеннарында һәм ярышларда перспективалы яшь спортчыларны карау һәм сайлап алу.

4.4. Спорт төрләре буенча спорт әзерлеге төркемнәрен формалаштыру тәртибе спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмалары тарафыннан мөстәкыйль рәвештә билгеләнә.

4.5. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмаларына керүче гражданнарны кабул итү тәртибе түбәндәге:

4.5.1. Укырга керүчеләрне шәхси сайлап алу нәтиҗәләре нигезендә кабул итү, укырга керүчеләрнең физик, психологик сәләтләрен һәм (яки) спорт әзерлеге буенча тиешле программаларны үзләштерү өчен кирәкле булган хәрәкәтләнү күнекмәләрен ачыклаудан гыйбарәт.

4.5.2. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасына керүчеләрне индивидуаль сайлап алуны оештыру һәм үткәрү максатларында кабул итү (биш кешедән дә ким булмаган) һәм апелляция (өч кешедән дә ким булмаган) комиссияләре оештырыла. Әлеге комиссияләрнең составлары спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасының боеру акты белән раслана.

Кабул итү һәм апелляция комиссияләре тренер-инструкторлык составыннан, башка белгечләрдән, шул исәптән спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыруда катнашучы әлеге спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасының медицина хезмәткәрләреннән төзелә. Апелляция комиссиясе спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасының кабул итү комиссиясе составына кермәгән хезмәткәрләре арасыннан төзелә. Кабул итү һәм апелляция комиссияләре секретаре әлеге комиссияләр составына кермәскә мөмкин.

Кабул итү һәм апелляция комиссияләре эшен оештыруны, спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы җитәкчесе тарафыннан балигъ булмаган укырга керүчеләрне, шулай ук балигъ булмаган балаларның законлы вәкилләрен шәхси кабул итүне оештыруны кабул итү комиссиясе секретаре башкара.

Кабул итү һәм апелляция комиссияләре эшчәнлеге регламенты спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасының локаль норматив акты белән раслана.

4.5.3. Документларны кабул итә башлаганчы бер айдан да соңга калмыйча, спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы үзенең мәгълүмат стендында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, алар белән укырга керүчеләр һәм аларның законлы вәкилләрен таныштыру максатында, түбәндәге мәгълүматны һәм документларны урнаштыра:

уставның күчермәсе;

спорт әзерлеге программалары буенча тренировкалар процессын дәүләт оештыруны регламентлый торган локаль норматив актлар;

кабул итү һәм апелляция комиссияләренең эш расписаниесе;

спорт әзерлеге программалары буенча тиешле елда бюджет урыннары саны, шулай ук укырга керүчеләр өчен вакантлы урыннар саны (булган очракта);

спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасына кабул итү өчен кирәкле документларны кабул итү сроклары;

тиешле елда укырга керүчеләрне шәхси сайлап алуны үткәрү вакыты;

укырга керүчеләрнең физик (хәрәкәтләнү) сәләтләренә һәм психологик үзенчәлекләренә карата куелган таләпләр;

шәхси сайлап алуны уздырганда кулланыла торган бәяләү (билге, баллар, үлчәү берәмлекләрендәге күрсәткечләр) системасы;

мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен индивидуаль сайлап алу шартлары һәм үзенчәлекләре;

укырга керүчеләрне индивидуаль сайлап алу процедурасы һәм (яки) нәтиҗәләре буенча апелляцияләр бирү һәм карау кагыйдәләре;

спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасына керүчеләрне кабул итү сроклары.

4.5.4. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасына кабул итү формасы спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы тарафыннан билгеләнгән укырга керүченең (законлы вәкилләрнең) язма гаризасы буенча гамәлгә ашырыла.

4.5.5. Укырга керүчеләр (законлы вәкилләр) спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасының локаль норматив акты белән билгеләнгән срокларда апелляция комиссиясенә индивидуаль сайлап алуны уздыру процедурасы буенча язма апелляция бирергә хокуклы.

4.6. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасына керүче затларны кабул итү спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы җитәкчесенең боеру акты (җитәкчесе боерыгы) белән, кабул итү яки апелляция комиссиясе карары нигезендә спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы тарафыннан билгеләнгән вакыт эчендә рәсмиләштерелә.

Укырга керүчеләрне индивидуаль сайлап алу нәтиҗәләре буенча укырга кергәннән соң вакантлы урыннар булган очракта гамәлгә куючы спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга өстәмә кабул итү хокукын бирә ала.

Вакантлы урыннарга кабул итү спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы тарафыннан билгеләнгән вакыт эчендә шәхси сайлап алу нәтиҗәләре буенча үткәрелә.

4.7. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыруның төп формалары булып тора:

төркемле һәм шәхси күнегүләр һәм теоретик дәресләр;

шәхси планнар буенча эш;

тренировка җыеннары;

спорт ярышларында һәм чараларда катнашу;

инструкторлык һәм судьялар практикасы;

медик-торгызу чаралары;

тест һәм контроль.

4.8. Спорт әзерлеге, спорт ярышларына әзерлек һәм спорт әзерлеге үтүче затлар актив ял итү (яңадан торгызу) ел әйләнәсе булсын өчен тренировка процессының состав өлеше (дәвамы) булган күнегүләр җыеннары оештырыла.

4.9. Спорт әзерлегенең шәхси планнары буенча эш спорт осталыгын һәм югары спорт осталыгын камилләштерү этапларында алып барыла.

4.10. Югары спорт осталыгы этабында программа буенча спорт әзерлеге узучы затларның максималь яше белән генә чикләнми.

4.11. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасында тренировкалар спорт әзерлеге федераль стандартларына (спорт төрләре буенча) туры китереп спорт әзерлеге программалары буенча исәпләнгән еллык уку (күнегүләр) планы нигезендә алып барыла.

4.12. Спорт әзерлеге программалары структурасына һәм эчтәлегенә карата таләпләр, шул исәптән спорт әзерлегенең һәр этабына карата аларның теоретик һәм гамәли бүлекләрен үзләштерүгә карата таләпләр спорт әзерлегенең (спорт төрләре буенча) федераль стандартлары белән билгеләнә.

4.13. Спорт әзерлеге программасы үз эченә алырга тиеш:

спорт әзерлеге этапларының дәвамлылыгы, спорт әзерлеге этапларына кабул итү өчен затларның минималь яше һәм спорт төре буенча спорт әзерлеге этапларында төркемнәрдә спорт әзерлеге узучы затларның минималь саны;

спорт төре буенча спорт әзерлеге этапларында спорт әзерлеге төрләре буенча тренировкалар процессы күләмнәре чагыштырмасы;

спорт төре буенча ярыш эшчәнлегенең планлаштырылган күрсәткечләре;

күнегүләр эше режимнары;

спорт әзерлеге узучы затларга медицина, яшь һәм психофизик таләпләр;

чик тренировкалар йөкләнеше;

ярышу эшчәнлегенең минималь һәм иң чик күләме;

экипировка, спорт инвентарьларына һәм җиһазларына карата таләпләр;

әзерлек төркемнәренең сан һәм сыйфат составына карата таләпләр;

индивидуаль спорт әзерлеге күләме;

еллык цикл структурасы (чорлар, этаплар, мезоцикллар исеме һәм дәвамлылыгы).

4.14. Программаның контроль системасы һәм зачет таләпләре үз эченә алырга тиеш:

физик сыйфатларның һәм тән төзелешенең спорт төре буенча нәтиҗәлелеккә йогынтысын исәпкә алып, спорт әзерлегенең һәр этабында спорт әзерлеге узучы затларны әзерләү критерийларын конкретлаштыру;

спорт әзерлегенең һәр этабында программаны тормышка ашыру нәтиҗәләренә карата таләпләр (аларны үтәү спорт әзерлеге узучы затны спорт әзерлегенең киләсе этабына күчерү өчен нигез бирә);

гомуми һәм махсус физик, спорт-техник һәм тактик әзерлекне контрольдә тоту төрләре, әзерлек этаплары һәм еллары буенча контроль сынаулар комплексы һәм контроль-күчү нормативлары, контроль уздыру сроклары;

спорт әзерлеге узучы затларның гомуми, махсус физик, техник-тактик әзерлеген бәяләү өчен контроль күнегүләр комплексы, тестлаштыру оештыру, медик-биологик тикшерү методлары һәм аны оештыру буенча методик күрсәтмәләр.

4.15. Спорт әзерлеге этапларына керү өчен затларның минималь яше, төркемнең тулылыгы һәм атнага күнегүләр йөкләнеше күләме нормативлары спорт төре буенча спорт әзерлеге программасы тарафыннан билгеләнә.

4.16. Төркемнәрдә дәресләрнең дәвамлылыгы спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасының локаль норматив акты белән билгеләнә. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмаларында атнага тәкъдим ителгән дәресләрнең кыска булуы һәм аларның дәвамлылыгы спорт әзерлегенең (спорт

төрләре буенча) федераль стандартлары һәм билгеләнгән санитар-гигиена нормаларына туры китереп билгеләнә.

4.17. Физик культура чаралары һәм спорт чаралары планы Төбәкара, бөтенроссия һәм халыкара физкультура чараларының һәм спорт чараларының бердәм календарь планы, Татарстан Республикасы физкультура чараларының һәм спорт чараларының календарь планнары нигезендә спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы тарафыннан формалаштырыла.

4.18. Спорт әзерлеге узучы затлар спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы тарафыннан спорт әзерлеге программасында булган физкультура чаралары һәм спорт чаралары планы, спорт ярышлары һәм спорт чаралары турындагы нигезләмәләр (регламентлар) нигезендә спорт ярышларына җибәрелә.

4.19. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасыннан спорт ярышларына җибәрелә торган затларны билгеләгәндә спорт әзерлеге узучы затларның спорт ярышларында катнашу өчен спорт әзерлеге федераль стандартлар белән билгеләнә торган түбәндәге алымнарга таяна:

катнашучы яшенең һәм җенесенең рәсми спорт ярышлары һәм спорт төре кагыйдәләре турындагы нигезләмәгә (регламентка) туры килүе;

Бердәм бөтенроссия спорт классификациясе һәм спорт төре кагыйдәләре нигезендә рәсми спорт ярышлары турындагы нигезләмәгә (регламентка) спорт квалификациясе дәрәҗәсенең туры килүе;

спорт әзерлеге планын үтәү;

алдан сайлап алу ярышлары узу;

спорт ярышларында катнашуга рөхсәт турында тиешле медицина бәяләмәсе булу;

допингка каршы гомумроссия кагыйдәләрен һәм халыкара допингка каршы оешмалар тарафыннан расланган допингка каршы кагыйдәләрне үтәү.

4.20. Спортчыларны сыйфатлы әзерләүне тәэмин итү максатыннан, спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмалары аны бергәләп тормышка ашыра алалар, шул исәптән челтәр багланышлар аша да. Белем бирү оешмалары һәм (яки) фәнни, медицина оешмалары һәм кирәкле ресурсларга ия булган башка оешмалар тарафыннан спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыруда челтәр хезмәттәшлегенең үзенчәлеге – кластерлы хезмәттәшлек:

а) белем бирү программасын турыдан-туры тормышка ашыручы дәүләт оешмасы буларак (тулысынча яки программаның нинди дә булса компоненты (модуле) өлешендә);

б) спорт әзерлеге программасын турыдан-туры тормышка ашыручы дәүләт оешмасы буларак (тулысынча яки программаның нинди дә булса компоненты (модуле) өлешендә));

в) элек бу дәүләт оешмасында укыту яки спорт әзерлеге узган, ләкин спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы башка дәүләт оешмасына күчкән спортчыны педагогик яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыручы дәүләт белем бирү оешмасы сыйфатында.

4.21. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасында медицина эшчәнлеге сәламәтлек саклау өлкәсендәге законнар нигезендә алып барыла. Спорт әзерлеге узучы затларны медицина белән тәэмин итү Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче затларга

(шул исәптән физкультура чараларын һәм спорт чараларын әзерләгәндә һәм үткәргәндә), шул исәптән оешмаларда спорт әзерлеген узарга, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнергә һәм (яки) «Хезмәткә һәм оборонага әзер» бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынаулар (тестлар) нормативларын үтәргә теләгән затларга медицина тикшерүе тәртибен дә кертеп, медицина ярдәме күрсәтүне оештыру тәртибе турында» 2016 елның 1 мартындагы 134н номерлы боерыгы нигезендә (алга таба – Тәртип) штаттагы медицина хезмәткәрләре һәм (яки) табиб-физкультура диспансерларының (бүлекләрнең) хезмәткәрләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Тәртип нигезендә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче затларга (шул исәптән физкультура чараларын һәм спорт чараларын әзерләгәндә һәм үткәргәндә) медицина ярдәме түбәндәге рәвештә күрсәтелә:

беренчел медик-санитар ярдәм;

махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле, медицина ярдәме;

ашыгыч, шул исәптән махсуслаштырылган ашыгыч медицина ярдәме, медицина эвакуациясен дә кертеп.

4.22. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмаларында спорт әзерлеге белән шөгыльләнергә теләгән затның медицина тикшерүе тирәнәйтелгән медицина тикшеренүләре программалары буенча үткәрелә.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүне матди-техник тәэмин итүгә карата таләпләр

5.1. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмаларының матди-техник базасына һәм инфраструктурасына гомуми шартлар спорт әзерлегенең (спорт төрләре буенча) федераль стандартлары белән билгеләнә.

5.2. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы санитар-эпидемиология кагыйдәләре һәм нормалары, стандартлар, техник шартлар таләпләренә җавап бирә торган һәм дәүләт хезмәтенең тиешле сыйфатын тәэмин итә торган җиһазлар, аппаратура һәм җайланмалар белән җиһазландырылырга тиеш.

## 6. Дәүләт хезмәте күрсәтү куркынычсызлыгына таләпләр

6.1. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмалары законнарда билгеләнгән тәртиптә юридик зат буларак теркәлергә тиеш.

6.2. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмалары бүлмәләре түбәндәгеләргә туры килергә тиеш:

«Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы федераль закон белән расланган янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләренә;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгынга каршы режим турында» 2012 елның 25 апрелендәге 390 номерлы карарына;

«Кешенең санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон белән расланган санитар-эпидемиология нормаларына.

Балалар өчен бүлмәләрне подвал һәм цоколь катларында урнаштыру рөхсәт ителми.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла торган предметлар һәм җиһазлар Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән санитар таләпләргә җавап бирергә тиеш. Күрсәтелгән биналарда дәүләт хезмәте күрсәтү яки балаларның тору шартларын тәэмин итү процессы белән бәйле булмаган җиһазлар булырга тиеш түгел.

6.3. Махсус җиһазлар, приборлар һәм аппаратура катгый рәвештә эксплуатация документларына туры китереп файдаланылырга, техник яктан төзек хәлдә булырга тиеш.

Төзексез махсус җиһазлар, приборлар һәм аппаратура алыштырылырга, ремонтланырга (ремонт ясалырга тиеш булса) яки эксплуатациядән алынган булырга тиеш.

6.4. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылык тота:

уставы белән билгеләнгән функцияләрне үтәү;

спорт төрләре буенча спорт әзерлеге программаларын тулы күләмдә тормышка ашыру;

тренировка процессын оештыру формаларының, алымнарының һәм чараларының спорт әзерлеге узучы затларның яшенә, мәнфәгатьләренә һәм ихтыяҗларына туры килүе;

тренировкалар барышында дәүләт хезмәтен алучыларның һәм спорт әзерлеген тормышка ашыручы дәүләт оешмасы хезмәткәрләренең тормышы һәм сәламәтлеге;

дәүләт хезмәтен алучыларның һәм спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы хезмәткәрләренең хокукларын һәм ирекләрен саклау.

6.5. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы җиһазланырга тиеш:

автоматик янгын сигнализациясе;

янгын турында хәбәр итү системасы;

кирәкле янгын сүндерү чаралары;

шәхси саклану чаралары;

эвакуацияләүне оештыру өчен кирәкле чаралар белән.

6.6. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасында:

күренә торган урыннарда янгын чыккан очракта кешеләрне эвакуацияләү планнары (схемалары) эленергә тиеш;

кешеләрне куркынычсыз һәм тиз эвакуацияләүне тәэмин итү буенча персоналның гамәлләрен билгели торган инструкция булырга тиеш;

кимендә ярты елга бер тапкыр спорт әзерлеге күрсәтүче дәүләт оешмасы хезмәткәрләрен эвакуацияләүгә җәлеп ителгән барлык хезмәткәрләрнең гамәли күнегүләре үткәрелергә тиеш.

## 7. Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итә торган таләпләр

7.1. Россия Федерациясе гражданнары булган, сәламәтлеге торышы буенча спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасына кабул итүгә карата каршылыклары булмаган индивидуаль сайлап алу үткән затларга бөтен календарь ел дәвамында дәүләт хезмәте күрсәтү гарантияләнә.

7.2. Дәресләр расписаниесе спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы администрациясе тарафыннан, спорт әзерлеге узучы затларның иң уңайлы хезмәт һәм

ял режимын булдыру өчен, яшь үзенчәлекләрен һәм билгеләнгән санитар-гигиена нормаларын исәпкә алып төзелә, спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмаларында дәресләр 8.00 сәгатьтән дә иртәрәк түгел, ә аларны тәмамлау – 20.00 сәгатьтән дә соңга калмыйча башкарылырга тиеш.

Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасының эш режимы аның уставы һәм оешманың башка локаль актлары белән регламентлана.

7.3. Балаларга уңайлы булсын өчен спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы әлеге Стандартның һәм законнарның барлык таләпләрен мәҗбүри үтәп, балаларның яшәү урынына якын булган дәүләт белем бирү оешмасы базасында дәүләт хезмәте күрсәтә ала.

7.4. Дәүләт хезмәте индивидуаль сайлап алу нәтиҗәләре буенча формалаштырылган дәүләт хезмәтен алучыларның рейтингына туры китереп күрсәтелә.

7.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору гариза характерына ия. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасында дәүләт хезмәте алучыга урын түбәндәге очракларда саклана:

1) спорт әзерлеген узучы затның яисә ата-ананың (законлы вәкилләрнең) авыру чорына;

2) спорт әзерлеге узучы затның санатор-курорт дәвалавы чорына;

3) спорт әзерлеген узучы зат булмаган башка очракларда җитди сәбәпләр аркасында документлар белән расланган.

7.6. Спорт әзерлеге узучы инвалидлар һәм мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен спортның адаптив төрләре буенча спорт әзерлегенең федераль стандартлары билгеләнә.

Спортның адаптив төрләре буенча спорт әзерлегенең әлеге стандартларында спортчылар үзләренең спортның адаптив төре белән шөгыльләнү өчен кирәк булган функциональ мөмкинлекләренә карап төркемнәр күрсәтелә (алга таба – функциональ төркемнәр).

7.7. Спорт әзерлеге төркемнәрен комплектлау, шулай ук спортның адаптив төрләре буенча күнегүләрне планлаштыру (төрле юнәлештәге күнегүләр йөкләнешләренең күләме һәм интенсивлыгы буенча) шөгыльләрен планлаштыру үсешнең гендер һәм яшь үзенчәлекләре, функциональ төркемнәр, шулай ук сәламәтлек халәтендә чикләүнең индивидуаль үзенчәлекләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

Адаптив физик культура инвалидларның һәм сәламәтлекләре чикләнгән затларның физик тернәкләндерүнең нәтиҗәле чараларын кулланучы физик культураның бер өлеше булуын исәпкә алып, спорт дисциплиналарын, функциональ төркемнәрне, шулай ук сәламәтлекләре чикләнгән шәхси үзенчәлекләрне исәпкә алып, физик тернәкләнүгә һәм социаль адаптациягә юнәлдерелгән дәресләр үткәрү тәкъдим ителә.

7.8. Физик мөмкинлекләре чикләнгән затлар, инвалид балалар һәм инвалидлар өчен дәүләт хезмәтләрен алу мөмкинлегеннән файдалану максатында спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы тәэмин итә:

а) күрү буенча сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен:

спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтларын, күрү буенча инвалидларның аерым ихтыяҗларын исәпкә алып, веб-контент һәм веб-сервисларның (WCAG) һәркем файдалана алуның халыкара стандартына адаптацияләү;

сукыр яисә начар күрүче булган дәүләт хезмәтен алучылар өчен файдалана алырлык булган урыннарда һәм җайлаштырылган формада (аерым ихтыяҗларны исәпкә алып) тренировка дәресләре расписаниесе турында белешмә мәгълүмат урнаштыру (эре рельеф-контраст шрифт белән башкарылырга (язма хәрефләренең биеклеге 7,5 см дан ким булмаска тиеш) (ак яки сары фонда) һәм Брайль шрифты белән кабатланырга тиеш);

дәүләт хезмәтләрен алучыга кирәкле ярдәм күрсәтүче ассистентның булуы;

басма материалларның альтернатив форматларын чыгару (эре шрифт яки аудиофайллар);

дәүләт хезмәте күрсәтүчене укыту сәгатьләренә сукыр һәм йөртүче эттән файдаланучы булган дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланучының этне урнаштыру өчен урын булган спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы бинасына керү;

б) ишетү буенча мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен:

күнегү дәресләре расписаниесе турында тавыш белешмәләренең визуаль кабатлануы (субтитрларны трансляцияләү мөмкинлеге булган мониторлар урнаштыру (мониторлар, аларның күләме һәм санын бина зурлыгын исәпкә алып билгеләргә кирәк);

мәгълүмат җиткерүнең тиешле тавышлы чаралары ярдәмендә;

в) терәк-хәрәкәт аппараты бозылулары булган затлар өчен спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасының уку бүлмәләренә, ашханә, бәдрәф һәм башка бүлмәләренә тоткарлыксыз керү мөмкинлеге булган, шулай ук күрсәтелгән бүлмәләрдә булу (пандуслар, култыксалар, киңәйтелгән ишек уемнары, лифтлар булу, биеклеге 0,8 метрдан артмаган стоек-барьерларны локаль киметү, махсус утыргычлар һәм башка җайланмалар булу).

7.9. Төркемнең санлы составы аңа физик мөмкинлекләре чикләнгән балаларны һәм (яки) инвалид балаларны, инвалидларны керткәндә кимергә мөмкин.

Уку төркемендә мөмкинлекләре чикләнгән затлар, инвалид балалар һәм инвалидлар саны 15 кешегә кадәр билгеләнә. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән, инвалид балалар һәм инвалидлар белән төркемнәрдә дәресләр дәүләт хезмәтләрен башка алучылар белән берлектә дә, шулай ук аерым классларда, төркемнәрдә яки спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы аерым дәүләт оешмаларында да оештырыла ала.

Дәүләт хезмәтен алучы сәламәтлекләре мөмкинлекләре чикләнгән, инвалид балалар һәм инвалидлар белән спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасында да, яшәү урыны буенча да индивидуаль эш алып барыла ала.

7.10. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашырганда инвалид балаларга һәм инвалидларга бушлай махсус дәреслекләр һәм уку әсбаплары, башка уку әсбаплары бирелә, шулай ук сурдотәрҗемәчеләр һәм тифлосурд тәрҗемәчеләр хезмәтләре күрсәтелә.

## 8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне кадрлар белән тәэмин итү дәрәҗәсенә карата таләпләр

8.1. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы квалификацияле белгечләр белән штат расписаниесе һәм төркемдә тәрбияләнүчеләр белән комплектланган санда тәэмин ителергә тиеш. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы персоналын комплектлау тәртибе аның уставы белән регламентлана.

8.2. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасында педагогик эшчәнлеккә югары яки урта һөнәри белемле, тиешле педагогик хезмәткәрләрнең вазыйфалары өчен билгеләнгән квалификация характеристикалары таләпләренә җавап бирә торган, шул исәптән түбәндәге таләпләргә туры килә торган югары яки урта һөнәри белемле затлар кертелә:

башлангыч әзерлек этабында – белгечлек буенча эш стажына карата таләпләр куелмыйча гына урта һөнәри белем яисә югары белем;

тренировка этабында (спорт специализациясе этабында) – урта һөнәри белем яисә югары белем, белгечлек буенча бер елдан да ким булмаган эш стажы;

спорт осталыгын һәм югары спорт осталыгын камилләштерү этапларында – югары белем һәм белгечлек буенча кимендә өч ел эш стажы булу.

8.3. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмаларына хезмәткәрләрне әзерләүне һәм хезмәткәрләрне өстәмә һөнәри белем бирүне түбәндәге периодлылык белән гамәлгә ашырырга киңәш ителә:

педагогик хезмәткәрләр (тренер-укытучылар, инструктор-методистлар) өчен – кимендә өч елга бер тапкыр;

спорт әзерлеген тормышка ашыруда турыдан-туры катнашучы, әмма педагогик хезмәткәрләр (тренерлар) булмаган белгечләр өчен – кимендә дүрт елга бер тапкыр;

җитәкчеләр, җитәкчеләр урынбасарлары, структур бүлекчәләр җитәкчеләре һәм төп персоналга карамаган башка белгечләр өчен – кимендә биш елга бер тапкыр.

## 9. Дәүләт хезмәте алучыларны мәгълүмати тәэмин итү дәрәҗәсенә карата таләпләр

9.1. »Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы таләпләре нигезендә спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы дәүләт хезмәтен алучыларга үз исемен, урынын (адресын) һәм эш режимын җиткерергә тиеш.

9.2. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы, аны дәүләт теркәвенә алу, теркәгән орган исеме, чираттагы финанс елына дәүләт йөкләмәсе күләме турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

9.3. Дәүләт хезмәтен алучыга Россия Федерациясе законнарында каралган һәм аның халык өчен үтемле булуын тәэмин итә торган теләсә кайсы формада спорт

әзерлеген, лицензия номеры, гамәлдә булу вакыты, шулай ук әлеге лицензияне биргән орган турында мәгълүмат җиткерелергә тиеш.

9.4. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы алучыга дәүләт хезмәтләре турында дөрес сайлау мөмкинлеген тәэмин итүче дөрес мәгълүмат бирергә, дәүләт хезмәтеннән файдалану кагыйдәләре һәм шартлары белән таныштырырга тиеш. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре турындагы мәгълүмат составына кертелергә тиеш:

спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы тарафыннан күрсәтелә торган төп дәүләт хезмәтләре исемлеге;

дәүләт хезмәтләренең характеристикасы;

Спорт әзерлегенең хәзерге стандарты һәм федераль стандартлары турында мәгълүматлар;

дәүләт хезмәтләренең сыйфаты, аларны күрсәтү шартлары турында мәгълүмат;

дәүләт хезмәтләрен алучыларның хезмәт сыйфатына йогынтысы турында мәгълүмат;

дәүләт хезмәтләрен алучыларның спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы хезмәткәрләре белән коммуникация чаралары турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтләрен нәтиҗәле һәм куркынычсыз күрсәтү кагыйдәләре һәм шартлары.

9.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүматта әлеге хезмәт күрсәтүче конкрет затка күрсәтелгән күрсәтмә булырга тиеш.

9.6. Мәгълүмат бирү ысулы һәм тәртибе Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнә.

9.7. Спорт әзерлеге узучы затларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) тренировкалар процессы барышы һәм эчтәлеге белән танышу мөмкинлеге тәэмин ителергә тиеш.

## 10. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

10.1. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы дәүләт хезмәте алучыга яисә ата-анага (законлы вәкилгә) дәүләт хезмәте күрсәтүдән түбәндәге очракларда баш тарта:

сайлап алынган спорт төре белән шөгыльләнү өчен ярамаган күрсәткечләр булса (сәламәтлек торышы турында медицина бәяләмәсе);

укырга керүче физик, психологик сәләтләрне һәм (яки) спорт әзерлеге буенча тиешле программаларны үзләштерү өчен кирәкле хәрәкәт күнекмәләрен ачыклаудан гыйбарәт индивидуаль сайлап алу узмаган.

## 11. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләренең тасвирламасы

11.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып Спорт әзерлеге программасын үзләштерү тора.

11.2. Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү сыйфатын бәяләү күрсәткечләре (индикаторлары) түбәндәге таблицада китерелгән:

| Т/с | Сыйфатны бәяләү индикаторы исеме, үлчәү берәмлеге | Исәпләү методикасы | Мәгълүмат чыганагы | Индикаторы иң чик әһәмияте | Үлчәү коэффициенты |
|---|---|---|---|---|---|
| | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. | Спорт әзерлеге буенча югары спорт осталыгы этабында спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча спорт әзерлеге федераль стандарты таләпләрен үтәгән затлар өлеше, процент | $\frac{A}{B} \times 100\%,$ монда: А – спорт әзерлеге буенча югары спорт осталыгы этабында спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча тиешле спорт төре буенча спорт әзерлеге федераль стандарты таләпләрен үтәгән затлар; В – югары спорт осталыгы этабында спорт әзерлеге узучы спортчыларның гомуми саны | «Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар буенча мәгълүматлар» № 5-ФК статистик күзәтү формасы («Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга Россия Федерациясе Спорт министр-лыгы тарафыннан статистик күзәтүне оештыру өчен статистик инструментарийны раслау турында» 22 ноябрь, 2017 ел, 773 номерлы Федераль дәүләт статистикасы хезмәте боерыгы белән расланган) | 80 | 8 |
| 2. | Спорт осталыгын камилләштерү этабында спорт әзерлеген узган һәм югары спорт осталыгы этабына кертелгән затлар өлеше, процент | $\frac{A}{B} \times 100\%,$ монда: А – спорт осталыгын камилләштерү этабында спорт әзерлеген узган һәм югары спорт осталыгы этабына кертелгән затлар; | «Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар буенча мәгълүматлар» № 5-ФК статистик күзәтү формасы («Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга Россия Федерациясе Спорт министр- | 10 | 7 |

| | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | B – спорт осталыгын камилләштерү этабында спорт әзерлеге узучы спортчыларның гомуми саны | лыгы тарафыннан статистик күзәтүне оештыру өчен статистик инструментарийны раслау турында» 22 ноябрь, 2017 ел, 773 номерлы Федераль дәүләт статистикасы хезмәте боерыгы белән расланган) | | |
| 3. | Тренировка этабында (спорт специализациясе этабы) спорт әзерлеген узган һәм спорт осталыгын камилләштерү этабына исәпләнгән затлар өлеше, процент | $\frac{A}{B}\times 100\%$, монда: A – тренировка этабында (спорт специализациясе этабы) спорт әзерлеген узган һәм спорт осталыгын камилләштерү этабына кертелгән затлар; B – тренировка этабында спорт әзерлеге узучы спортчыларның гомуми саны (спорт специализациясе этабы) | «Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар буенча мәгълүматлар» № 5-ФК статистик күзәтү формасы («Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга Россия Федерациясе Спорт министрлыгы тарафыннан статистик күзәтүне оештыру өчен статистик инструментарийны раслау турында» 22 ноябрь, 2017 ел, 773 номерлы Федераль дәүләт статистикасы хезмәте боерыгы белән расланган) | 20 | 7 |

| | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 4. | Башлангыч әзерлек этабында спорт әзерлеген узган һәм тренировка этабына кертелгән затлар өлеше (спорт специализациясе этабы), процент | $\frac{А}{В} \times 100\%$,<br>монда:<br>А – башлангыч әзерлек этабында спорт әзерлеге узган һәм тренировка этабына кертелгән затлар (спорт специализациясе этабы);<br>В – башлангыч әзерлек этабында спорт әзерлеге узучы спортчыларның гомуми саны | «Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар буенча мәгълүматлар» № 5-ФК статистик күзәтү формасы («Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга Россия Федерациясе Спорт министрлыгы тарафыннан статистик күзәтүне оештыру өчен статистик инструментарийны раслау турында» 22 ноябрь, 2017 ел, 773 номерлы Федераль дәүләт статистикасы хезмәте боерыгы белән расланган)) | 70 | 7 |
| 5. | Дәүләт хезмәтен алучыларның, ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) нигезле шикаятьләре өлеше, процент | $\frac{Ж_о}{Ж} \times 100\%$,<br>монда:<br>$Ж_о$ – хисап чорында дәүләт хезмәтен алучыларның, ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) нигезле шикаятьләре саны;<br>Ж – хисап чорында дәүләт хезмәтен алучыларның гомуми шикаятьләре саны | мониторинг нәтиҗәләре буенча билгеләнә | 0 | 9 |
| 6. | Дәүләт хезмәтеннән файдаланучыларның, дәүләт хезмәт күрсәтүенең сыйфаты | $\frac{\frac{О_к + О_д}{2}}{О_{общ}} \times 100\%$, | мониторинг нәтиҗәләре буенча билгеләнә | 80 | 9 |

| | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | һәм мөмкинлегеннән канәгать булган ата-аналарның (законлы вәкилләренең) өлеше, процентов | монда:<br>$О_к$ – хезмәт күрсәтү сыйфатыннан канәгать сораштырылучылар саны;<br>$О_д$ – хезмәт күрсәтүнең файдалана алырлык булуыннан канәгать сораштырылучылар саны;<br>$О_{общ}$ – сораштырылучы хезмәт алучылар, ата-аналар (законлы вәкилләре) гомуми саны | | | |
| 7. | Тормыш эшчәнлеге иминлеген бозу очраклары булу, берәмлек | хезмәтне саклау таләпләрен бозу, оешманың матди базасының торышы канәгатьләнмәслек булу белән бәйле очраклар саны | мониторинг нәтиҗәләре буенча билгеләнә | 0 | 6 |
| 8. | Шәһәр, төбәк, федераль, халыкара чаралар буенча дәүләт хезмәтләрен алучыларның гомуми санында конкурсларда, фестивальләрдә, смотрларда, күргәзмәләрдә, конференцияләрдә, ярышларда һәм башка шундый чараларда катнашучы дәүләт хезмәтен алучылар саны, процент | $\frac{А}{В} \times 100\%$,<br>монда:<br>А – конкурсларда, фестивальләрдә, смотрларда, күргәзмәләрдә, конференцияләрдә, ярышларда һәм башка шундый чараларда катнашучы дәүләт хезмәтләрен алучылар саны;<br>В – дәүләт хезмәтләрен алучыларның гомуми саны | мониторинг нәтиҗәләре буенча билгеләнә | 30 | 8 |

| | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 9. | Уку программаларын үтәү, процент | $\frac{A}{B} \times 100\%$, монда: A – программа буенча үткәрелгән сәгатьләрнең саны; B – программада каралган сәгатьләр саны | мониторинг нәтиҗәләре буенча билгеләнә | 100 | 7 |
| 10. | Контингентның сакланышы, процент | $\frac{A}{B} \times 100\%$, монда: A – спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда шөгыль-ләнүче, уку елы ахырына дәүләт хезмәтен алучылар саны; B – спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда шөгыль-ләнүче уку елы башына дәүләт хезмәтен алучылар саны | «Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар буенча мәгълүматлар» № 5-ФК статистик күзәтү формасы («Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга Россия Федерациясе Спорт министр-лыгы тарафыннан статистик күзәтүне оештыру өчен статистик инструментарийны раслау турында» 22 ноябрь, 2017 ел, 773 номерлы Федераль дәүләт статистикасы хезмәте боерыгы белән расланган) | 70 | 9 |
| 11. | Төркемнәрнең норматив тулылыгына факттагы мөнәсәбәт, процент | $\frac{A}{B} \times 100\%$, | мониторинг нәтиҗәләре буенча билгеләнә | 80 | 10 |

| | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | монда:<br>А – төркемнәрнең фактлагы тулылыгы;<br>В – төркемнәрнең норматив тулылыгы | | | |

## 12. Дәүләт хезмәте стандартының туры килмәве һәм үтәлмәве буенча шикаятьләрне бирү, теркәү һәм карау тәртибе

12.1. Шикаять кәгазьдә яисә электрон формада спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасына язмача бирелә. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына җибәрелә.

12.2. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасының, хезмәткәрләренең һәм спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасының, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталыннан файдаланып почта аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук дәүләт хезмәтен алучының шәхси кабул итүе вакытында кабул ителергә мөмкин.

12.3. Шикаять дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы законнарда билгеләнгән таләпләргә җавап бирергә тиеш.

12.4. Татарстан Республикасы спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасына кергән шикаять, аны теркәгән көннән алып 15 эш көне эчендә каралырга тиеш, ә спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы шикаять биргән очракта, дәүләт хезмәтен алучыдан документлар кабул итүдән баш тарткан йә кертелгән опечаткаларны һәм хаталарны төзәткәндә яисә мондый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогын бозган очракта – аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

12.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы закон нигезендә карар кабул ителә, һәм аны кабул иткән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, дәүләт хезмәтен Алучыга язма рәвештә һәм дәүләт хезмәтләрен электрон формада алучының теләге буенча шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

12.6. Шикаять җавапта канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмасы гамәлләре турында мәгълүмат бирелә, шулай ук бирелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында дәүләт хезмәте алучыга алга таба дәүләт хезмәте күрсәтүгә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

12.7. Шикаять дәүләт хезмәте күрсәтүчегә җавапта канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

12.8. Шикаятьне карау барышында яки карау нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки җинаять билгеләре билгеләнгән очракта, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы закон нигезендә шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

12.9. Граждан (аның законлы вәкиле) Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле карарларга һәм гамәлләргә (гамәл

кылмавына) карата суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

## 13. Дәүләт хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе

13.1. Гомумроссия спорт федерацияләре һәм аккредитацияләнгән төбәк спорт федерацияләре һәм аларның вәкилләре спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмалары тарафыннан тиешле спорт төрләре буенча федераль стандартларны үтәүгә Россия Федерациясе Спорт министрлыгының «Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмалары тарафыннан спорт әзерлегенең федераль стандартларын үтәүне контрольдә тоту тәртибен раслау турында» 2013 ел, 16 август, 636 нчы боерыгы белән расланган Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы дәүләт оешмалары тарафыннан спорт әзерлегенең федераль стандартларын үтәүне контрольдә тоту тәртибенең 2 пункты нигезендә җәмәгать контролен гамәлгә ашырырга хокуклы.

13.2. Дәүләт хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфатының Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган сыйфатның билгеләнгән стандартларына туры килү-килмәвен бәяләү тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 14. Дәүләт хезмәтен түләүле яки бушлай күрсәтү

14.1. Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә.

---